- 1920 елга кадәр авыл Нократ губерниясе Алабуга өязе Салагыш волостена кергән.
- Нәни бәзәкәлеләр өчен беренче ясле-бакча 1933 елда ачыла. Сугыш чорында мәктәпкәчә учреждениенең кечкенә бинасында һәркайсында 25-25, 30ар сабый булган биш төркем тәрбияләнә.
- Бәзәкәле Шәмсетдин Усманов алтынчы башкорт полкы составында Россиядән француз гаскәрләрен кууда катнаша, шуның өчен истәлекле “1812 ел” көмеш медале белән бүләкләнә.
- Бөек Ватан сугышы елларында фронтка 635 бәзәкәле китә, аларның 241 кеше яу кырында мәңгелеккә ятып кала.